СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2025 г. Заинск № 12

**Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 185 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмә турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 3 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставы белән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 185 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 11 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советының 28.07.2016 ел № 50,15.12.2016 ел № 63, 02.03.2017 ел № 71, 08.06.2017 ел № 81, 12.10.2017 ел № 87, 22.04.2019 ел № 145, 14.10.2019 ел № 165, 11.03.2020 ел № 177, 03.06.2020 ел № 182, 11.11.2020 ел № 12, 03.03.2021 ел № 27, 27.12.2021 ел № 76, 27.01.2023 ел № 119, 10.08.2023 ел № 127, 30.11.2023 ел № 148,18.04.2024 ел № 158, 13.06.2024 ел № 164, 18.10.2024 ел № 175, 27.03.2025 елдан 189 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен югары белем булу, вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.».

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башлыгы урынбасары С. В. Максимовка йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**